| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ<br>КОМИТЕТ КУКМОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА<br>КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02.05.2023 Кукмара ш. № 259

«Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләренә һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) гражданнарның гаиләләренә социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2022 елның 03 ноябрендәге 381 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында

«Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар гаиләләренә һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) гражданнар гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» 2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 20 мартындагы 291 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә **карар бирәм:**

1. «Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләренә һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) гражданнарның гаиләләренә социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2022 елның 03 ноябрендәге 381 номерлы карарына (Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2022 елның 10 ноябрендәге 387 номерлы һәм 2022 елның 24 ноябрендәге 403 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән), түбәндәге эчтәлекле абзацларны өстәп, үзгәреш кертергә:

«18 яшькә кадәрге балалар арасыннан гаилә әгъзаларына һәм бер ата-анага (законлы вәкилгә) Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә урнашкан ведомство карамагындагы муниципаль мәдәният учреждениеләре үткәрә торган чараларга бушлай йөрү хокукы бирү;

7 яшьтән алып 18 яшькә кадәрге балалар арасыннан гаилә әгъзаларына һәм бер ата-анага (законлы вәкилгә) Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә даими рәвештә кеше йөртү муниципаль

маршрутларында гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында (таксидан тыш) бушлай йөрү хокукы бирү;».

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2023 елның 1 маеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында (http://kukmor.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А.Х. Гарифуллин**